**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 14 ноябре** **№ 90**

**2014 елның 19 ноябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль Районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 114 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 36 маддәсе нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2014 елның 19 ноябрендәге “Физик затларның милкенә салым турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 114 нчы номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә”:

1.1. Карарның 2 пунктының 1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әлеге пунктның 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан салым салу объектларында урнашкан гаражларын һәм машина-урыннарын;

1.2. Карарның 2 пунктының 2 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“фатирларны, фатир өлешләрен, бүлмәләрне;”;

1.3. Карарның 2 пунктының 3 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак йортларны, торак йортларның бер өлешен;”;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт белән тулыландырырга:

“3.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче 18 яшькәчә өч яки күбрәк балалары булган гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның балалары физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә”

2. Әлеге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган срокта үз көченә керә.

2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә, 1 пунктчасының икенче абзацындагы, 2

пунктчасының икенче абзацындагы, 2 пунктның 3 пунктчасының икенче абзацындагы (әлеге Карар редакциясендә) нигезләмәләрнең гамәлдә булуы кагыла.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстн Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27нче йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Бортас авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**“Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы,**
**“Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге**
**Советы Рәисе** **Р.С.Сагдиев**